Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«10» апрель 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 10 апрендә узган: «2024 елда Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, СВОда катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Тумба торак пунктында ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү» мәсьәләсе белән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 110 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 58 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 57 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныrга.

2024 елда Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, СВОда катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Тумба торак пунктында ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.Н. Осипов

Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Осипов